КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 25 июль г.Казань № 716

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1278 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2021 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Россия Федерациясенең аерым субъектларында 2022 елда Өлкән яшьтәге тәрбиягә мохтаҗ гражданнар һәм инвалидларны озак вакытлы тәрбияләү системасының үрнәк моделен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 29 декабрендәге 929 номерлы боерыгы белән расланган Өлкән яшьтәге тәрбиягә мохтаҗ гражданнар һәм инвалидларны озак вакытлы тәрбияләү системасының үрнәк моделендә билгеләнгән мәгънәсендә кулланыла.»;

2.1 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) чит кеше ярдәменә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү нәтиҗәләре буенча чит кеше

тәрбияләвенә мохтаҗ булуның өченче дәрәҗәсе билгеләнгән» сүзләрен «өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) тәрбияләүгә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү нәтиҗәләре буенча тәрбияләүгә мохтаҗ булуның өченче дәрәҗәсе билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «чит кеше» сүзләрен төшереп калдырырга, «тәрбияләвенә» сүзен «тәрбияләүгә» сүзенә алмаштырырга;

4.1 пунктның икенче абзацында «чит кеше» сүзләрен төшереп калдырырга, «тәрбияләвенә» сүзен «тәрбияләүгә» сүзенә алмаштырырга;

4.2 пунктта «чит кеше» сүзләрен төшереп калдырырга, «тәрбияләвенә» сүзен «тәрбияләүгә» сүзенә алмаштырырга;

4.4 пунктның 1 пунктчасында «чит кеше» сүзләрен төшереп калдырырга, «тәрбияләвенә» сүзен «тәрбияләүгә» сүзенә алмаштырырга;

4.6 пунктның 2 пунктчасындагы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«өлкән яшьтәге гражданның (инвалидның) тәрбияләүгә индивидуаль ихтыяҗын билгеләү бланкы;»;

7.1 пунктта «чит кеше» сүзләрен төшереп калдырырга, «тәрбияләвенә» сүзен «тәрбияләүгә» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2021 – 2022 елларда «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә субсидия бирү тәртибендә:

1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.»;

2.3 пунктка «и» пунктчасыннан соң түбәндәге эчтәлекле «к» пунктчасын өстәргә:

«к) оешманың, индивидуаль эшмәкәрнең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавы турында белешмә кәгазе (әлеге исемлекләрдән өземтәләрне теркәп).»;

3.1 пунктның икенче абзацында «Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга» сүзләрен «, оешмалар, индивидуаль эшмәкәрләр (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет

кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә оешмаларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга»; сүзләренә алмаштырырга;

V бүлекнең исемендә «, максаты» сүзен төшереп калдырырга;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Вәкаләтле орган оешмаларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра. Оешмаларның, индивидуаль эшмәкәрләрнең субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерү дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карары белән расланган 2021 – 2022 елларда «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә субсидия бирү тәртибенең 1.6 пунктындагы дүртенче абзацының, 2.1 пунктындагы алтынчы абзацының, 2.3 пунктындагы «б» пунктчасының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин